**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 3 и 5 Закона Республики Татарстан «О санитарно-эпидемиологическом благополучии населения»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 января 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 20 июня 2006 года № 42-ЗРТ «О санитарно-эпидемиологическом благополучии населения» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 6 (I часть); 2012, № 3, № 7 (I часть); 2014, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I); 2021, № 77 (часть I), № 93 (часть I) следующие изменения:

1) абзац шестой части 1 статьи 3 после слова «населения,» дополнить словами «санитарно-гигиеническому просвещению населения и»;

2) в статье 5:
а) часть 1 дополнить словами «, санитарно-гигиенического просвещения населения и пропаганды здорового образа жизни»;
б) дополнить частью 5 следующего содержания:
«5. В целях формирования санитарно-гигиенической культуры в обществе и мотивации граждан к здоровому образу жизни проводится санитарно-гигиеническое просвещение населения посредством распространения знаний, необходимых для формирования здорового образа жизни, включая здоровое питание и отказ от вредных привычек, профилактики заболеваний, сохранения и укрепления здоровья, знаний по иным вопросам обеспечения санитарно-эпидемиологического благополучия населения, в том числе с использованием средств массовой информации, информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», печатной продукции (памяток, буклетов, плакатов и другой), социальной рекламы, а также при проведении мероприятий в организованных коллективах, индивидуальных консультаций граждан.

Порядок, условия и формы проведения санитарно-гигиенического просвещения населения и порядок осуществления контроля за ним устанавливаются в соответствии с законодательством об образовании.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
03 февраля 2023 года
№ 6-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацына «укыту,» сүзеннән соң «халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм укыту» сүзләреннән соң «, халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җәмгыятьтә санитария-гигиена культурасын һәм гражданнарда сәламәт яшәү рәвешенә мотивация булдыру максатларында халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту үткәрелә, ул, дөрес туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, сәламәт яшәү рәвешен булдыру, авыруларны профилактикалау, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен кирәкле белемнәрне, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүнең башка мәсьәләләре буенча белемнәрне тарату юлы белән, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, басма продукциялардән (белешмәләрдән, буклетлардан, плакатлардан һәм башкалардан), социаль рекламадан файдаланып, шулай ук оештырылган коллективларда чаралар, гражданнарга индивидуаль консультацияләр үткәргәндә гамәлгә ашырыла.

Халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуны үткәрү тәртибе, шартлары һәм рәвешләре һәм аны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе мәгариф турындагы законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 февраль
№ 6-ТРЗ